ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

2025 ел 17 ноябре №1

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең М. Вахитов исемендәге авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең М. Вахитов исемендәге авылында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең М.Вахитов исемендәге авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлар; СВО зонасына мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары (РФ Гаилә кодексының 2 ст. нигезендә), РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегәннәр, шулай ук башка ведомстволар (Росгвардия, ЧВК, РЖД һ. б.) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (РФ Гаилә кодексының 2 ст. нигезендә), 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә. Түләүләр күләме түбәндәге категория гражданнар өчен гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә: күпбалалы гаиләләр; көндезге уку йортлары студентлары; чакырылыш буенча сроклы хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр; тыл хезмәтчәннәре.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймаларын тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, халыкны су белән тәэмин итү.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Кәримов